**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Өченче Бөгелде торак пунктында гражданнар җыены карары**

**14.11.2020** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Өченче Бөгелде торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлардан кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлегенең Өченче Бөгелде авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- Озерная урамына керә торган юлны ремонтлау;
- урам яктырткычларын ремонтлау;
- зират төзекләндерү,зират коймаларын ремонтлау;
- торак пункт атамасы белән юл күрсәткеч билгеләре алу һәм урнаштыру.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Аксар авыл җирлеге башлыгы__________________ Ю.И.Гильманов